КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 18 октябрь г.Казань № 942

«Казан халык сәнгате һөнәрләре техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының гамәлдәге «Казан халык сәнгате һөнәрләре техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенең төрен үзгәртү юлы белән «Казан халык сәнгате һөнәрләре техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – техникум) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Техникумны гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы гамәлгә ашыра дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына:

60 көн эчендә «Казан халык сәнгате һөнәрләре техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе уставына (алга таба – Устав) тиешле үзгәрешләр кертергә һәм аларны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

Уставка кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 30 көн эчендә техникумның күзәтүчеләр советы составын расларга;

30 көн эчендә элек «Казан халык сәнгате һөнәрләре техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенә теркәлгән, техникум эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле дәүләт мөлкәте исемлеген, шулай ук беркетелә торган күчемсез милек объектларына техник документацияне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшырырга;

ел саен техникум Уставы белән каралган төп эшчәнлек нигезендә техникум өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт биремен расларга.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына билгеләнгән тәртиптә Уставка кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң:

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тапшырган исемлек нигезендә элек оператив идарә итү хокукында «Казан халык сәнгате һөнәрләре техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенә теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән аеруча кыйммәтле күчмә мөлкәтне техникумга беркетергә;

120 көн эчендә әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә техникумга беркетелә торган күчемсез милек объектлары урнашкан җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында тапшыруны тәэмин итәргә.

5. Техникум тарафыннан дәүләт биремен үтәүне финанслар белән тәэмин итү әлеге максатларга тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган акча кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән берлектә әлеге карарның 3, 4, 7 пунктларын үтәгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасының тиешле норматив хокукый актларын, аларны әлеге карарның 1 пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының җыелма бюджет исемлегенә тиешле үзгәрешләр кертергә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин